ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Зеленодольск **КАРАР**

**05.12.2019** шәһәре **№ 2667**

Бюджет кредитын кире кайтару, процент һәм башка түләүләрне түләү буенча юридик затның, муниципаль берәмлекнең йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүгә бирелә торган банк гарантиясе һәм поручительлек ышанычлылыгын бәяләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 93$^{2}$ статьясындагы 3 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Бюджет кредитын кире кайтару, процент һәм башка түләүләрне түләү буенча юридик затның, муниципаль берәмлекнең йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүгә бирелә торган банк гарантиясе һәм поручительлек ышанычлылыгын бәяләү тәртибен кушымтада бирелгәнчә расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигы Д.С. Анисимовка әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Җитәкченең беренче урынбасары А.В. Старостин

Расланган
Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән
_________________ № ______________

# Бюджет кредитын кире кайтару, процент һәм башка түләүләрне түләү буенча юридик затның, муниципаль берәмлекнең йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүгә бирелә торган банк гарантиясе һәм поручительлек ышанычлылыгын бәяләү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексының $93^2$ статьясындагы 3 пункты нигезендә эшләнгән һәм бюджет кредитын кире кайтару, процент һәм башка түләүләрне түләү буенча юридик затның, муниципаль берәмлекнең йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүгә бирелә торган банк гарантиясенең һәм поручительлекнең ышанычлылык күрсәткечләрен билгели.

2. Банк гарантиясе һәм поручительлекнең ышанычлылыгы банк яисә башка кредит оешмасының (алга таба-гарант) һәм поручительләрнең финанс тотрыклылыгы белән билгеләнә.

3. Банк гарантиясе һәм поручительлекнең ышанычлылыгы дигәндә, әлеге Тәртип максатларында Гарант һәм поручительның бюджет кредитын кире кайтару буенча юридик зат, муниципаль берәмлек (алга таба – алучы) йөкләмәләрен үз вакытында һәм тулы күләмдә үти алуы аңлашыла.

4. Тәэмин итү күләме бирелә торган бюджет кредиты күләмен, аның буенча процентларны һәм тиешле килешүдә каралган башка түләүләрне капларга тиеш.

5. Йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итүне рәсмиләштерү Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан (алга таба – Зеленодольск муниципаль районы) бюджет кредиты бирелгәнчегә кадәр башкарыла.

6. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы (алга таба - Финорган) банк гарантиясен һәм поручительлелекне башкара , бюджет кредитларын тәэмин итү буенча бирелә торган бәяне гамәлгә ашыра.

## II. Банк гарантиясенең ышанычлылыгын бәяләү

2.1. Әлеге Тәртип максатларында гарант түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

бетерелү, үзгәртеп кору, банкротлык процессында булмаска;

административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган тәртиптә эшчәнлек туктатылмаган булырга;

Зеленодольск муниципаль районы алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча кичектерелгән (җайга салынмаган) бурычлар, салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән

бурыч, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы тарафыннан элегрәк бирелгән муниципаль гарантияләр буенча җайга салынмаган йөкләмәләре булмаска;

банк операцияләрен башкару өчен Россия Федерациясе Үзәк банкының генераль лицензиясе булу;

«Россия Федерациясе банкларында кертемнәрне иминләштерү турында» 2003 елның 23 декабрендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе банкларындагы физик затларның кертемнәрен мәҗбүри иминиятләү системасында катнашу (Россия банкының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында соңгы хисап датасына урнаштырылган рәсми мәгълүматлар);

Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан «Россия Федерациясе Үзәк банкы (Россия Банкы) турында» 2002 елның 10 июлендәге 86-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән мәҗбүри нормативларны бозган өчен чаралар кулланылмау (Россия Федерациясе Үзәк банкының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында соңгы хисап датасына урнаштырылган рәсми мәгълүматлар).

2.2.Әлеге тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган Гарант, Финорганга түбәндәге документлар тапшыра:

а) алучының йөкләмәләрен гарантияләүгә ризалашу турында гарант хаты;

б) гарант тарафыннан раслаган гарантның гамәлгә кую документлары күчермәләре;

в) гарант тарафыннан расланган салым органында исәпкә кую турында таныклык, юридик затларның Бердәм дәүләт реестрында дәүләт теркәвенә алу турында таныклык яки язу кәгазе күчермәләре;

г) гарантның бетерелү, үзгәртеп кору, банкротлык процессында булмавын раслый торган документлар;

д) гарантның аерым башкарма органы, башка вәкаләтле затның гарант исеменнән килешүләр эшләүгә һәм гарантның баш хисапчысы (сайлап кую турында карар, билгеләп кую турында боерык, вазыйфага керү турында боерык, контракт күчермәсе, ышаныч кәгазе) вәкаләтләрен раслаучы гарант тарафыннан расланган документлар, шулай ук нотариаль расланган имза үрнәкләре һәм гарантның мөһере оттискысы;

е) гарант идарәсенең вәкаләтле органы тарафыннан банк гарантиясен бирү буенча алыш-биреш итүгә ризалыгын (хуплавын) раслый торган документның нотариаль расланган күчермәсе (алучының йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүгә);

ж) банк операцияләрен башкару өчен Россия Федерациясе Үзәк банкының генераль лицензиясенең нотариаль расланган күчермәсе;

з) соңгы хисап датасына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча гарантның бурычлары булмавын раслаучы салым органы белешмәсе;

и) Гарант тарафыннан раслаган бухгалтерлык балансы һәм хисап финанс елы өчен һәм соңгы хисап датасына керемнәр һәм чыгымнар турында хисап;

к) әлеге Тәртипнең 2.2 пунктының «а» пунктчасы нигезендә хат белән мөрәҗәгать иткән елдан алдагы елда гарантның бухгалтерлык хисаплылыгының дөреслеге турында гарант раслаган аудиторлык бәяләмәсе күчермәсе;

л) Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнә торган форма буенча гарантның үз акчаларын (капиталын) исәпләү һәм, рөхсәт ителгән күрсәткечләр диапазонын китереп, соңгы хисап датасына мәҗбүри нормативлар күрсәткечләре;

м) Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнә торган форма буенча мәҗбүри нормативлар турында мәгълүмат;

н) Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнә торган форма буенча Гарант активларының сыйфаты турында мәгълүмат;

о) җитәкче кул куйган һәм Гарант мөһере белән расланган гарантның чиста активларын исәпләү;

п) Россия Федерациясе Үзәк банкының соңгы ярты ел дәвамында мәҗбүри резерв таләпләренең үтәлеше турында, клиентларның исәп-хисап документларын вакытында түләмәү фактларының булмавы турында, Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан гарантка карата кулланылган мәҗбүри йогынты чаралары булмау турында Россия Федерациясе Үзәк банкы белешмәсе;

р) Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан вәкаләтле вазыйфаи затлар кандидатураларын килештерүне раслый торган документлар

Гарант әлеге пунктның «в», «г», «з» пунктчаларында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, Финорган аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

2.3. Гарантның финанс хәле түбәндәге күрсәткечләр белән билгеләнә:

соңгы финанс елында һәм агымдагы елның узган чорында зыянга эшләмәү;

гарант активларының I һәм II категория сыйфаты, гарантның гомуми активларның кимендә 50 процентын тәшкил итәргә тиеш;

гарантның Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнгән мәҗбүри нормативларга туры килүе;

гарантның чиста активлары күләме күрсәтелгән бюджет кредитының өчкә тапкырланган суммасыннан түбән булырга тиеш түгел.

2.4.Гарантның Финорганга кергән документлары алар кергән көнне теркәлә.

2.5. Гарант тарафыннан тапшырылган документлар әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында билгеләнгән документлар исемлегенә туры килмәгән очракта, Финорган, документларны теркәү датасыннан биш эш көненнән дә соңга калмыйча, аларны кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, гарантка кире кайтара.

2.6.Гарант тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында билгеләнгән исемлегенә туры килгән очракта, Финорган тарафыннан банк гарантиясенең ышанычлылыгын бәяләү үткәрелә. Финорган тапшырылган документларны 15 көн дәвамында , документларны теркәү датасыннан алып, эш көннәрендә ,гарантның әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында

каралган таләпләргә туры килү-килмәвен һәм, әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән күрсәткечләрне исәпкә алып, аның финанс хәлен билгеләүне күздә тотып тикшерә.

Документларны карау нәтиҗәләре буенча Финорган гарантның финанс тотрыклылыгы һәм аның бюджет кредитын кире кайтару буенча алучының йөкләмәләрен үз вакытында һәм тулы күләмдә үтәүне булдыру турында бәяләмә әзерли, бу хакта гарантка Бәяләмәне әзерләү датасыннан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итела.

## III. Поручительлек ышанычлылыгын бәяләү

3.1.Әлеге Тәртип максатларында поручитель түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

бетерелү, үзгәртеп кору, банкротлык процессында булмаска;

административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган тәртиптә эшчәнлеге туктатылмаган булырга;

Зеленодольск муниципаль районы алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча кичектерелгән (җайга салынмаган) бурыч һәм салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурыч, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы тарафыннан элегрәк бирелгән муниципаль гарантияләр буенча җайга салынмаган йөкләмәләр булмаска.

3.2. Әлеге тәртипнең 3.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган поручитель, Финорганга түбәндәге документлар тәгъдим итә:

а) алучының йөкләмәләренә поручитель булырга ризалашу турында поручительнең хаты;

б) поручитель раслаган гамәлгә кую документларының күчермәләре;

в) поручитель раслаган салым органында исәпкә кую турында таныклык, юридик затларның Бердәм дәүләт реестрында дәүләт теркәвенә алу турында таныклык яки язу кәгазе күчермәләре;

г) поручитель раслаган поручительнең аерым башкарма органы, башка вәкаләтле затның поручитель исеменнән килешүләр эшләүгә һәм поручительнең баш хисапчысы (сайлап кую турында карар, билгеләп кую турында боерык, вазыйфага керү турында боерык, контракт күчермәсе, ышаныч кәгазе) вәкаләтләрен раслаучы документлар, шулай ук нотариаль расланган имза үрнәкләре һәм поручительнең мөһере оттискысы;

д) поручитель идарәсенең вәкаләтле органы тарафыннан поручительлек бирү буенча алыш-биреш итүгә ризалыгын (хуплавын) раслый торган документның нотариаль расланган күчермәсе (алучының йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүгә);

е) поручительнең бетерелү, үзгәртеп кору, банкротлык процессында булмавын раслый торган документлар;

ж) поручитель тарафыннан хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиянең нотариаль расланган күчермәсе (Россия Федерациясе законнарында поручитель тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек

лицензия нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләнгән очракта);

з) кредит оешмаларында ачылган поручительнең гамәлдәге счетлары турында салым органы тарафыннан расланган белешмә;

и) банклар тарафыннан поручительнең исәп-хисап счетларында акчалар булу һәм аларның картотекага суммасы турында бирелгән белешмәләр;

к) бухгалтер балансы, хисап финанс елы өчен финанс нәтиҗәләре турында хисап, поручитель раслаган соңгы хисап датасына, аларны кабул итү турында салым органы тамгасы белән һәм төп чаралар турында баланс статьяларының расшифровкаларын кушып, матди кыйммәтләргә керемнәре, озак сроклы финанс кертемнәре, кыска сроклы финанс кертемнәре, дебитор бурычлары, озак сроклы бурычлар, кыска сроклы кредитлар һәм займнар, кредит бурычлары турында хисап (һәр төр бурыч буенча);

л) соңгы хисап датасына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча поручительнең бурычлары булмавын раслаучы салым органы белешмәсе;

м) әлеге Тәртипнең 2.2 пунктының «а» пунктчасы нигезендә хат белән мөрәҗәгать иткән елдан алдагы елда поручительнең бухгалтерлык хисаплылыгының дөреслеге турында поручитель раслаган аудиторлык бәяләмәсе күчермәсе (Россия Федерациясе законнары нигезендә ел саен аудитор тикшерүе узарга тиешле юридик затлар өчен);

н) җитәкче кул куйган һәм поручитель мөһере белән расланган поручительнең чиста активларын исәпләү.

Поручитель әлеге пунктның «в», «е», «л» пунктчаларында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, Финорган аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

3.3. Финорганга кергән поручитель документлары алар кергән көнне теркәлә.

3.4. Поручитель тарафыннан тапшырылган документлар әлеге Тәртипнең 3.2 пунктында билгеләнгән документлар исемлегенә туры килмәгән очракта, Финорган, документларны теркәү датасыннан биш эш көненнән дә соңга калмыйча, аларны кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, поручителенә кире кайтара.

3.5. Поручитель тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 3.2 пунктында билгеләнгән исемлегенә туры килгән очракта, Финорган тарафыннан поручительлекнең ышанычлылыгына бәя бирелә. Финорган тапшырылган документларны, документларны теркәү датасыннан алып эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көнлек срокта,гарантның әлеге Тәртипнең 3.1 пунктында каралган таләпләргә туры килү-килмәвен һәм, әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә поручительнең финанс хәлен бәяләү методикасы нигезендә поручительнең финанс хәлен анализлый.

Бюджет кредитын кайтару буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү буенча поручительләр булып торучы юридик затларның финанс хәлен анализлау, күрсәтелгән юридик затлар «Фитч Рейтингс» (Fitch Ratings) яки «Стандарт энд Пурс» (Standard & Poor 's) рейтинг агентлыклары классификациясе буенча «ВВ-» рейтинг агентлыклары дәрәҗәсеннән ким

булмаган яисә «Мудис Инвесторс Сервис» (Moody' s Investors Service) рейтинг агентлыгы классификациясе буенча «Ba3» (“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рейтинг агентлыкларының рәсми мәгълүматлары) дәрәҗәсеннән ким булмаган очракта үткәрелергә мөмкин.

Документларны карау нәтиҗәләре буенча Финорган поручительнең финанс тотрыклылыгы һәм аның бюджет кредитын кире кайтару буенча алучының йөкләмәләрен үз вакытында һәм тулы күләмдә үтәү сәләте турында бәяләмә әзерли, бу хакта поручительгә Бәяләмәне әзерләү датасыннан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

Бюджет кредитын кире кайтару, процент һәм башка түләүләрне түләү буенча юридик затның, муниципаль берәмлекнең йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүгә бирелә торган банк гарантиясе һәм поручительлек ышанычлылыгын бәяләү тәртибенә кушымта

Поручительнең финанс хәлен бәяләү методикасы

1. Поручительнең финанс хәлен бәяләү өчен финанс индикаторларының өч төркеме кулланыла:

ликвидлык коэффициенты;

үзенең һәм заем акчаларының нисбәте коэффициенты;

рентабельлек күрсәткече.

Исәп-хисап түбәндәге башлангыч мәгълүмат нигезендә башкарыла:

1 нче форма (бухгалтерлык балансы);

2 нче форма (финанс нәтиҗәләре турында хисап).

2. Ликвидлык коэффициенты

2.1. Ликвидлык коэффициентлары төркеме өч күрсәткечтән тора:

абсолют ликвидлык коэффициенты;

тиз ликвидлык коэффициенты;

агымдагы ликвидлык коэффициенты.

2.2. Абсолют ликвидлык коэффициенты К1 түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$К1 = \frac{\text{ден.средства } (1250) + \text{кр.фин. вложения } (1240)}{\text{тек. обязательства } (1500 - 1530 - 1540)},$$

биредә:

ден. сред - кассада һәм исәп-хисап счетында акча (балансның 1250 нче

юлы);

кр.фин.вложения - поручительның хисап чоры ахырына алынган кыска сроклы финанс чыгымнары (акцияләр, вексельләр, облигацияләр, бирелгән займнар һ.б.) суммасы. Аларга мөрәҗәгать итү (түләү) вакыты хисап датасыннан яки операция циклының дәвамлылыгыннан соң 12 айдан артмаган,әгәр 12 айдан артса (балансның 1240 нчы юлы) ;

тек.обязательства - хисап датасыннан соң 12 айдан да ким булмаган вакытка поручительнең кыска вакытлы финанс йөкләмәләре. Күрсәткеч V баланс бүлеге нәтиҗәсе (1500 юл юл), киләсе чор керемнәре (1530 нче юл) һәм бәяләү йөкләмәләре (1540 нчы юл) аермасы буларак килеп чыга.

2.3. Тиз ликвидлык коэффициенты К2 хуҗалык әйләнешеннән акчаны оператив рәвештә азат итү һәм булган финанс йөкләмәләрен түләү мөмкинлеген күрсәтә. Күрсәткеч түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$К2 = \frac{\text{деб. задолженность}(1230) + \text{кр. фин. вложения}(1240) + \text{ден. средства}(1250)}{\text{тек. обязательства } (1500 - 1530 - 1540)},$$

биредә:

деб.задолженность -дебитор бурычы, аны түләү ел дәвамында көтелә (балансның 1230 нчы юлы);

кр.фин.вложения -хисап чоры ахырына алынган кыска сроклы финанс чыгымнары (акцияләр, вексельләр, облигацияләр, бирелгән займнар һ.б.) суммасы. Аларга мөрәҗәгать итү (түләү) вакыты хисап датасыннан яки операция циклының дәвамлылыгыннан соң 12 айдан артмаган,әгәр 12 айдан артса (балансның 1240 нчы юлы .);

ден.средства - кассада һәм исәп-хисап счетында акча (балансның 1250 нче юлы);

тек.обязательства -хисап датасыннан соң 12 айдан ким булган вакытка поручительнең кыска вакытлы финанс йөкләмәләре. Күрсәткеч V баланс бүлеге нәтиҗәсе (1500 юл юл) һәм киләсе чор (1530 нче юл) керемнәре һәм бәяләү йөкләмәләре (1540 нчы юл) аермасы буларак килеп чыга.

2.4. Агымдагы ликвидлык коэффициенты К3 түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$К3 = \frac{\text{оборотные активы } (1200)}{\text{кр. обязательства } (1500 - 1530)},$$

биредә:

оборотные активы - әйләнештәге активлар (1200 нче юл);

кр. обязательства -хисап датасыннан соң 12 айдан да ким булган вакытка поручительнең кыска вакытлы финанс йөкләмәләре. Күрсәткеч V баланс бүлеге нәтиҗәсе (1500 юл юл) һәм киләсе чор (1530 нче юл) керемнәре аермасы буларак килеп чыга.

3. Үзенең һәм заем акчаларының нисбәте коэффициенты.

Үзенең һәм заем акчалары нисбәте коэффициенты К4 түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$К4 = \frac{\text{собственный капитал } (1300)}{\text{заемный капитал } (1500 + 1400 - 1530)},$$

биредә:

собственный капитал -үз капиталы һәм резервлары (1300 нче юл);

заем капиталы-финанс бурычлары. Күрсәткеч булачак чорларның керемнәрен (балансның 1530 нчы юлы) исәпкә алмыйча, кыска сроклы һәм озак сроклы йөкләмәләр (балансның 1400 һәм 1500 нче юлы) суммасы буларак килеп чыга.

4. Рентабельлек күрсәткече

4.1. Рентабельлек күрсәткече түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$К_5 = \frac{\text{прибыль от продаж } (2200)}{\text{выручка } (2110)},$$

биредә:

прибыль от продаж-продукцияне сатудан табыш (финанс нәтиҗәләре турында хисапның 2200 нче юлы);

выручка- керем (финанс нәтиҗәләре турында хисапның 2110 нчы юлы).

5. Финанс хәлен бәяләүне төзү

5.1. Һәр база индикаторы өчен иң яхшы һәм иң начар чик күрсәткече билгеләнә.

5.2. Алынган күрсәткечкә һәм иң чик күрсәткечләргә нигезләнеп, һәр күрсәткеч өчен өч категориянең берсе билгеләнә. Күрсәткечләрнең иң чик күрсәткечләре һәм күрсәткечләрнең факттагы күрсәткечләренә карап категорияне сайлау кагыйдәсе 1 нче таблицада китерелгән.

1 нче таблица

Күрсәткечләрнең иң чик күрсәткечләрен һәм күрсәткечләрнең факттагы күрсәткечләренә карап категорияне сайлау

| Коэффициентлар | 1 категория (яхшы күрсәткеч) | 2 категория (канәгатьләнерлек күрсәткеч ) | 3 категория (канәгатьләнмәслек күрсәткеч) |
|---|---|---|---|
| $К_1$ | 0,2дән артыграк | 0,1-0,2 | 0,1дән кимрәк |
| $К_2$ | 0,8 дән | 0,5-0,8 | 0,5 тән кимрәк |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | артыграк | | |
| $К_3$ | 2,0 дән артыграк | 1,0-2,0 | 1,0 дән кимрәк |
| $К_4$ | | | |
| сәүдә предприятиеләре | 0,6 дән артыграк | 0,4-0,6 | 0,4тән кимрәк |
| башка тармак предприятиеләре | 1,0 дән артыграк | 0,7-1,0 | 0,7 кимрәк |
| $К_5$ | 0,15 дән артыграк | 0,0-0,15 | 0,0 дән кимрәк (рентаб.түгел) |

5.3. Җыелма бәянең күрсәткече (S) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = Вес_1 \text{ x } Категория_1 + Вес_2 \text{ x } Категория_2 + Вес_3 \text{ x } Категория_3 + Вес_4 \text{ x } Категория_4 + Вес_5 \text{ x } Категория_5,$$

биредә:
$Вес_1$ -җыелма бәяләүдә Кi күрсәткеченең авырлыгы, i = 1, 2, 3, 4 яки 5.
Күрсәткечләрнең авырлыгы билгеләре 2 нче таблицада.
Категорияi-Кi күрсәткеченең әһәмияте булган категория.
Категорияi: 1, 2 яки 3.

2 нче таблица. Җыелма бәяне исәпләгәндә кулланыла торган күрсәткечләрнең авырлыгы

| Күрсәткеч | Күрсәткечнең авырлыгы |
|---|---|
| К1 абсолют ликвидлык коэффициенты | 0,11 |
| К2 тиз ликвидлык коэффициенты | 0,05 |
| К3 агымдагы ликвидлык коэффициенты | 0,42 |
| К4 үзенең һәм заем акчаларының нисбәте | 0,21 |
| К5 рентабельлек коэффициенты | 0,21 |

5.4. Җыелма бәяләүнең әһәмияте нигезендә поручительнең финанс хәле:
җыелма бәянең күрсәткече 1,05 тән артмаса, яхшы була;
җыелма бәя 1,05 дән артык, әмма 2,4 тән артмаса, канәгатьләнерлек;
җыелма бәянең күрсәткече 2,4 дән артып китсә, канәгатьләнмәслек була.
Поручительнең чиста активлары күләме бюджет кредитының өч тапкырга тигез суммасыннан ким булырга тиеш түгел.